АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО
РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«______» ____________________20 г.** **№ ___________**

**2012 елның 10 февралендәге “Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында”гы 12 номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү турында**

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында”гы ФЗ-273 номерлы Федераль законның 12 нче статьясының 1 нче, 2 нче һәм 3 нче өлешләре, 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында”гы ФЗ-79 номерлы Федераль законның 20 нче статьясының 2 нче өлеше нигезендә һәм Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 22 апрелендәге “Аларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең чыгымнары, шулай ук үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар җиткерергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында”гы УП-329 номерлы Указын үтәү максатында

БОЕРАМ:

ФЗ1. 2012 елның 10 февралендәге “Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентылында дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында”гы 12 номерлы боерыкка (алга таба - боерык) түбәндәге үзгәрешләрне

кертергә:

Боерыкның 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгындагы, аларга билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында белешмә бирү мәҗбүри булган һәм шулай ук аларны алмаштырганда дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында белешмә бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Исемлеген (алга таба - Исемлек), расларга (Кушымта)”;

боерыкның 2 пунктындагы 2.1 пункт өлешен яңа редакциядә бәян итәргә: “Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин, дәүләт хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында хезмәт килешүе шартларында оешмадагы вазыйфага куелу һәм (яки) әлеге оешмада ай дәвамында граждан-хокукый килешүе (граждан-хокукый килешүләре) шартларында йөз мең сумнан артык бәяләнүче эшләрне башкару (әлеге оешмада хезмәтләр күрсәтү) хокукына ия, әгәр әлеге оешманың дәүләт, (административ) идарәсенең аерым функцияләре дәүләт граждан хезмәткәренең вәкаләт (хезмәт) бурычларына кергән булса, дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибен һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләүгә карата таләпләрнең үтәлеше буенча тиешле комиссиянең ризалыгы белән”;

боерыкның 2 пунктының 2.2 пункт өлешен яңа редакциядә бәян итәргә: “Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфаларын башкарган гражданин, дәүләт хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында боерыкның 2 пунктының 2.1 пункт өлешендә күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләрне күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокукый килешүләрен төзегәндә эш бирүчегә үзенең соңгы хезмәт урыны турындагы мәгълүматларны җиткерергә бурычлы”;

боерыкның 2 пунктының 2.3 пункт өлешен яңа редакциядә бәян итәргә: “Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәтендәге вазыйфаларны башкарган гражданин

тарафыннан, дәүләт хезмәтеннән куылганнан соң, әлеге пунктның 2.2 пункт өлешендә каралган таләпләрнең үтәлмәве әлеге гражданин белән эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) карата төзелгән хезмәт яисә граждан-хокукый килешүнең бетерелүенә китерә”;

боерыкның 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Кадр эшчәнлеген алып бару буенча җаваплы хезмәткәргә Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен таныштырып чыгарга”.

2. Кушымтаны яңа теркәлүче редакциядә бәян итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Якупов Л.Г.

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентылыгының
2013 елның 1 августындагы
116/2 лс номерлы боерыгы белән
расланган
Кушымта

**Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгындагы, аларга билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында белешмә бирү мәҗбүри булган һәм шулай ук аларны алмаштырганда дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында белешмә бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының**
**Исемлеге**

| №№ пп | Вазыйфаның исеме | Вазыйфаларның күләме |
|---|---|---|
| **Җитәкчелек** | | |
| 1 | Җитәкченең беренче урынбасары | 1 |
| 2 | Җитәкче урынбасары | 2 |
| **Инвестиция проектлары экспертизасы бүлеге** | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 2 |
| **Инвестиция проектларына булышлык итү һәм теркәү бүлеге** | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 2 |
| 3 | Әйдәп баручы консультант | 1 |
| **Мәгълүмати-аналитик бүлек** | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| **Дәүләти-шәхси хезмәттәшлекне үстерү бүлеге** | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| **Юридик бүлек** | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| **Финанс исәбе һәм дәүләт сатып алулары бүлеге** | | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| **Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү секторы** | | |
| 1 | Секторның җитәкчесе | 1 |
| **Матди-техник тәэмин итү секторы** | | |
| 1 | Секторның җитәкчесе | 1 |
| | Барысы | 18 |